ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2 | д. им. М. Вахитова | 05.11.2025

Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең
М. Вахитов исемендәге авылында үзара салым кертү һәм
аннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына 22.11.2013 ел № 909 (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авылында гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 17 ноябренә М. Вахитов ис. авыл, Үзәк ур., 24 йорт  адресы буенча, авыл клубы бинасында 10 сәг 00 м. билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: «Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (су җыю скважинасын ремонтлау)

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Каримов